УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Федосеевская, 36, г. Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ
Федосеев ур., 36, Казан шәһәре, 420111

Телефон, факс (843) 221-77-85, сайт: www.gtn.tatarstan.ru, эл.почта: gostehnadzorrt@mail.ru

ПРИКАЗ
27.08.2021

Казан шәһәре

БОЕРЫК
№ 01-05/221 - пр

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең ведомство бүләкләре турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2007 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең дәүләт граждан хезмәткәрләрен, хезмәткәрләрен хезмәт эшчәнлегендәге югары казанышлары өчен, шулай ук Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенә йөкләнгән бурычларны хәл итүдә ярдәм күрсәтүче затларны бүләкләү системасын камилләштерү максатларында,

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең түбәндәге ведомство бүләкләрен гамәлгә куярга:

«Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Мактаулы инженер-инспекторы» күкрәк билгесе;

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең Мактау грамотасы;

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең Рәхмәт хаты;

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе дипломы.

2. Кушымталарда бирелгәннәрне расларга:

«Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Мактаулы инженер-инспекторы» күкрәк билгесе турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең Мактау грамотасы турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең Рәхмәт хаты турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе дипломы турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе.

3. Бүләкләүгә материаллар әзерләү, ведомство бүләкләрен исәпкә алу һәм бирү эшен оештыру, шулай ук бүләкләү документларын рәсмиләштерү буенча методик җитәкчелек итүне Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең оештыру-хокукый һәм кадрлар эше бүлегенә йөкләргә.

4. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең ведомство бүләкләре турында» 2018 елның 31 гыйнварындагы 01-05/55-пр номерлы;

«Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең «Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең ведомство бүләкләре турында» 2018 елның 31 гыйнварындагы 01-05/55-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 1 октябрендәге 01-05/252-пр номерлы.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче Р.Р. Зыятдинов

Татарстан Республикасы Дәүләт
техник күзәтчелек идарәсенең
27.08.2021 ел, № 01-05/221-пр
боерыгы белән расланды

«Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Мактаулы инженер-инспекторы» күкрәк билгесе турында нигезләмә

1. «Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Мактаулы инженер-инспекторы» күкрәк билгесе белән Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсендә (алга таба – Идарә) кимендә 10 ел эшли торган затлар бүләкләнә:

күпьеллык намуслы хезмәте һәм Татарстан Республикасында үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың, аттракционнарның техник торышына дәүләт күзәтчелеге бурычларын хәл итүдәге казанышлары өчен;

үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы, аттракционнарны эксплуатацияләү кагыйдәләрен үтәү буенча дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга юнәлтелгән чараларны эшләү һәм гамәлгә кертүгә зур өлеш керткән өчен;

Идарә эшчәнлеген камилләштерү һәм нәтиҗәлелеген арттыру буенча аеруча мөһим бурычларны үтәгән өчен;

Идарә эшчәнлегенә бәйле закон һәм норматив хокукый актларны эшләүгә зур өлеш керткән өчен;

Идарә күзәтчелегендә торган үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың, аттракционнарның техник торыш дәрәҗәсен шактый арттыру һәм техник эксплуатацияләү кагыйдәләр үтәлеше тәэмин итү мөмкинлеген бирә торган инициативалы гамәлләр өчен;

кешеләрнең гомерен саклап калганда, аварияләр яки табигый бәла-казаларны булдырмауда яки аларны бетерүдә, хезмәт вазыйфаларын башкарганда хокукка каршы гамәлләрне булдырмауда күрсәткән батырлык һәм фидакарьлек өчен.

Күкрәк билгесенең тасвирламасы һәм рәсеме әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында бирелгән.

2. Күкрәк билгесе таныклык белән тапшырыла. Күкрәк билгесенә таныклык формасы әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында бирелгән.

3. Күкрәк билгесе һәм аңа таныклык Идарә җитәкчесе яки аның йөкләмәсе буенча башка затлар тарафыннан бүләкләнә торган затның төп эш урыны буенча тантаналы шартларда тапшырыла.

4. Күкрәк билгесе күкрәкнең уң ягында йөртелә.

5. Идарәнең Күкрәк билгесе белән бүләкләнгән хезмәткәрләренең хезмәт кенәгәсенә яки хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматларга бүләкләү турында язу теркәлә.

6. Күкрәк билгесе белән кабат бүләкләү гамәлгә ашырылмый. Югалганы урынына алмаш итеп Күкрәк билгесенең дубликаты бирелми. Күкрәк билгесенә таныклык югалган очракта, Идарә карары нигезендә таныклык дубликаты бирелергә мөмкин.

«Татарстан Республикасы Дәүләт
техник күзәтчелек идарәсенең
Мактаулы инженер-инспекторы»
күкрәк билгесе турындагы
нигезләмәгә 1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Мактаулы инженер-инспекторы» күкрәк билгесенең тасвирламасы һәм рәсеме

1. «Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Мактаулы инженер-инспекторы» күкрәк билгесе көмеш төсендә, өлешчә кабарып тора торган күппочмактан гыйбарәт, өске өлешендә – таралып китә торган биш көмеш нурлар бәйләме белән, ә аскы өлешендә «Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе» дип алтынсу төсендә язылган кызыл фигуралы эмаль тасма белән әйләндереп алынган.

2. Билгенең зәңгәр эмаль белән капланган үзәк өлешендә алтын төсле Закон баганасының рельефлы стильләштерелгән сурәте урнашкан һәм аңа көмеш төстәге техник билге сурәте төшерелгән.

3. Үзәк өлеш 30 мм диаметрындагы алтын төсле тешле тәгәрмәч рәсеме белән коймаланган, әйләнәсе буйлап кара төстә «Мактаулы инженер-инспектор» дип язылган. Тешле тәгәрмәч сурәте – алтынсу төсендә.

4. Билгенең икенче ягында аның теркәү билгесе чокылган.

5. Билгенең гомуми үлчәме: биеклеге – 35 мм, киңлеге – 35 мм.

6. Күкрәк билгесе каптыргыч һәм бөҗра ярдәмендә биеклеге 15 мм һәм киңлеге 25 мм булган, өске һәм аскы өлешләре кысалап алынган турыпочмаклы пластинкадан гыйбарәт алтынсу төсендәге тимер калыпка тоташа.

7. Калыпның нигезе буйлап уентыклар китә, аның эчке өлеше горизонталь полосалар булып урнашкан яшел, ак һәм кызыл төсләрдәге ялтыравык тасма белән тарттырылган.

8. Калыпның икенче ягында билгене киемгә эләктерү өчен каптыргыч бар.

«Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Мактаулы инженер-инспекторы» күкрәк билгесенең рәсеме




«Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең

Мактаулы инженер-инспекторы»
күкрәк билгесе турындагы
нигезләмәгә 2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең
Мактаулы инженер-инспекторы» күкрәк билгесенә таныклык
тасвирламасы һәм аның рәсеме

1. «Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Мактаулы инженер-инспекторы» күкрәк билгесенә таныклык бланкы ведомство бүләге белән бүләкләнүне раслый торган документ булып тора.

2. Таныклык бланкының үлчәме ачык килеш 156 x 115 мм һәм ябылган халәтендә 78 x 115 мм. Зәңгәр яисә кызыл төсендәге тыгыз тонык кәгазьдә әзерләнә, бастырып чыгару – офсет һәм туры линия буенча бөгү.

3. Таныклыкның тышкы ягында өске якта «Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе» дип язылган, ике интервалдан соң үзәктә – баш хәрефләр белән «ТАНЫКЛЫК» язуы, бер интервалдан соң юл хәрефләре белән «Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Мактаулы инженер-инспекторы» күкрәк билгесенә» дип язылган, ике интервалдан соң Идарә эмблемасы урнашкан. Эмблема һәм язулар офсетлы алтын белән башкарылган.

4. Таныклыкның ачыла торган сул ягында фамилия өчен яссы сызык, исем өчен яссы сызык һәм ата исеме (булган очракта) өчен яссы сызык, алар астында «ТАНЫКЛЫК» сүзе һәм номер билгесе куелган. Таныклыкларны теркәү һәм исәпкә алу эшен оештыру-хокукый һәм кадрлар эше бүлеге башкара.

5. Таныклыкның ачыла торган уң ягында «Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Мактаулы инженер-инспекторы» күкрәк билгесе белән бүләкләнде» дип язылган, аскарак ике интервал аша вазыйфа атамасы өчен яссы сызыклар, вазыйфа атамасы астында бүләкләү турында боерыкның датасы һәм номеры өчен реквизитлар урнаша.

Алгы ягы

Татарстан Республикасының
Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе

ТАНЫКЛЫК

«Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Мактаулы инженер-инспекторы» күкрәк билгесенә



Икенче ягы

_______________________________________
(фамилиясе)

_______________________________________
(исеме)

_______________________________________
(ата исеме (булган очракта)

ТАНЫКЛЫК

№ _______

«Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Мактаулы инженер-инспекторы» күкрәк билгесе белән бүләкләнде

_______________________________________
_______________________________________
_______________________________________
_______________________________________
_______________________________________

Боерык: «_____» ________ ________

№ ________

Татарстан Республикасы Дәүләт
техник күзәтчелек идарәсенең
27.08.2021 ел, № 01-05/221-пр
боерыгы белән расланды

## Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең Мактау грамотасы турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең Мактау грамотасы (алга таба – Мактау грамотасы) кешеләрнең гомере, сәламәтлеге һәм мөлкәте өчен куркынычсызлык тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне саклау өлешендә – тракторларның, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка машиналарның һәм аларга тагылмаларның техник торышына, агросәнәгать комплексында – машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү кагыйдәләре үтәлешенә дәүләт күзәтчелеге өлкәсендәге казанышлар өчен, шулай ук хезмәт вазыйфаларын үрнәк башкарган, күпьеллык һәм мактауга лаеклы хезмәтләр өчен бүләк булып тора.

2. Мактау грамотасы белән Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы хезмәткәрләре, дәүләт граждан хезмәткәрләре, оешма, предприятие, учреждение, җәмәгать берләшмәләре коллективлары һәм хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе хезмәткәрләре (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе) бүләкләнә:

- Татарстан Республикасының дәүләт техник күзәтчелек системасын оештыру, торгызу һәм үстерүгә зур өлеш керткән өчен;
- югары һөнәри осталык, мактауга лаек эш һәм хезмәттәге уңышлар өчен;
- Татарстан Республикасының дәүләт техник күзәтчелек системасында күпьеллык һәм намуслы хезмәт өчен;
- Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү өлкәсендә кешеләрнең гомере, сәламәтлеге һәм мөлкәте өчен куркынычсызлык белән тәэмин итү эшендә югары нәтиҗәләргә ирешкән өчен;
- мактауга лаек һәм нәтиҗәле дәүләт граждан хезмәте өчен;
- һөнәри бәйрәмнәр һәм юбилей даталары уңаеннан.

3. Мактау грамотасы белән әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән, әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән өлкәдә кимендә 2 еллык эш стажы булган яки үз эшчәнлеген гамәлгә ашырган һәм кимендә 1 ел элек Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Рәхмәт хаты белән билгеләнгән затлар бүләкләнә.

4. Агросәнәгать комплексы оешмалары хезмәткәрләренә бүләкләү материаллары оешмалар үтенече буенча карала.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе хезмәткәрләренә бүләкләү материаллары бүләкләү өчен кандидат эшли торган

структур бүлекчә җитәкчесе үтенече буенча һәм Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе җитәкчесе урынбасары белән килештереп карала.

6. Хезмәткәрләргә бүләкләү материаллары бүләкләү өчен кандидатның казанышларын бәян итеп һәм аның хезмәт эшчәнлеге турында белешмәне күрсәтеп, нигезләнгән тәкъдим булган очракта, билгеләнгән формада тапшырыла.

7. Җитәкче составын (оешма җитәкчесе, урынбасарлар, бүлекләрнең җитәкчеләре, баш белгечләр) бүләкләү турындагы үтенечкә хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүдә бурычлар булмавы турындагы белешмә һәм оешмадагы уртача хезмәт хакы турындагы белешмәләр теркәлә.

8. Иҗтимагый берләшмәләр (оешмалар) Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе каршында үзләренең штатында булган хезмәткәрләрне бүләкләү турында үтенеч белән чыга ала.

9. Мактау грамотасы белән бүләкләү Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе боерыгы нигезендә башкарыла.

10. Ел дәвамында дисциплинар җәза алган затлар Мактау грамотасы белән бүләкләнергә тиеш түгел.

11. Мактау грамотасы Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе җитәкчесе яисә аның йөкләмәсе буенча башка затлар тарафыннан бүләкләнүченең төп эш урыны буенча тантаналы шартларда бирелә.

12. Мактау грамотасы белән бүләкләнгән Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе хезмәткәренең хезмәт кенәгәсенә яки хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматларга бүләкләү турында язу теркәлә.

13. Югалган Мактау грамотасы урынына Мактау грамотасының дубликаты бирелми.

14. Мактау грамотасы белән яңадан бүләкләүгә алдагы бүләкләүдән соң кимендә өч ел узгач кына тәкъдим итәргә мөмкин.

Татарстан Республикасы Дәүләт
техник күзәтчелек идарәсенең
27.08.2021 ел, № 01-05/221-пр
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең Рәхмәт хаты турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең Рәхмәт хаты (алга таба – Рәхмәт хаты) кешеләрнең гомере, сәламәтлеге һәм мөлкәте өчен куркынычсызлык тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне саклау өлешендә – тракторларның, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка машиналарның һәм аларга тагылмаларның техник торышына, агросәнәгать комплексында – машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү кагыйдәләре үтәлешенә дәүләт күзәтчелеге өлкәсендәге казанышлар өчен, шулай ук хезмәт вазыйфаларын үрнәк башкарган, күпьеллык һәм мактауга лаеклы хезмәтләр өчен ведомство бүләге булып тора, шул исәптән:

– Татарстан Республикасының дәүләт техник күзәтчелек системасын оештыру, торгызу һәм үстерүгә зур өлеш керткән өчен;

– югары һөнәри осталык, мактауга лаек эш һәм хезмәттәге уңышлар өчен;

– Татарстан Республикасының дәүләт техник күзәтчелек системасында күпьеллык һәм намуслы хезмәт өчен;

– Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсе) машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү өлкәсендә кешеләрнең гомере, сәламәтлеге һәм мөлкәте өчен куркынычсызлык тәэмин итү эшендә югары нәтиҗәләргә ирешкән өчен;

– мактауга лаек һәм нәтиҗәле дәүләт граждан хезмәте өчен;

– һөнәри бәйрәмнәр һәм юбилей даталары уңаеннан.

2. Рәхмәт хаты белән әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән өлкәләрдә кимендә 1 еллык эш стажы булган түбәндәге хезмәткәрләр бүләкләнә:

– Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре;

– Татарстан Республикасының башка министрлыклары һәм ведомстволарыннан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре;

– федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре;

– предприятиеләр, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр һәм учреждениеләр (шул исәптән фәнни, мәгариф һәм башка учреждениеләр) җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре.

3. Агросәнәгать комплексы оешмалары хезмәткәрләренә бүләкләү материаллары оешмалар үтенече буенча карала.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе хезмәткәрләренә бүләкләү материаллары бүләкләү өчен кандидат эшли торган структур бүлекчә җитәкчесе үтенече буенча һәм Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе җитәкчесе урынбасары белән килештереп карала.

5. Федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, башка министрлыклар һәм ведомстволар хезмәткәрләре өчен бүләкләү материаллары аларның үтенече буенча карала. Бу очракта бүләкләү өчен кандидатның казанышларын бәян итеп, нигезле тәкъдим әзерләнә һәм аның хезмәт эшчәнлеге турында белешмә бирелә.

6. Җитәкче составын (оешма җитәкчесе, урынбасарлар, бүлекләрнең җитәкчеләре, баш белгечләр) бүләкләү турындагы үтенечкә хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүдә бурычлар булмавы турындагы белешмә һәм оешмадагы уртача хезмәт хакы турындагы белешмәләр теркәлә.

7. Иҗтимагый берләшмәләр (оешмалар) Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе каршында үзләренең штатында булган хезмәткәрләрне бүләкләү турында үтенеч белән чыга ала.

8. Рәхмәт хаты белән бүләкләү Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе боерыгы нигезендә башкарыла.

9. Рәхмәт хаты Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе җитәкчесе яисә аның йөкләмәсе буенча башка затлар тарафыннан бүләкләнүченең төп эш урыны буенча тантаналы шартларда бирелә.

10. Ел дәвамында дисциплинар җәза алган затлар Рәхмәт хаты белән бүләкләнергә тиеш түгел.

11. Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе хезмәткәренең хезмәт кенәгәсенә яки хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматларга бүләкләү турында язу теркәлә.

12. Рәхмәт хатының дубликаты бирелми.

13. Рәхмәт хаты белән яңадан бүләкләү өчен алдагы бүләкләүдән соң кимендә бер ел узгач кына тәкъдим итәргә мөмкин.

Татарстан Республикасы Дәүләт
техник күзәтчелек идарәсенең
27.08.2021 ел, № 01-05/221-пр
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе дипломы турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе дипломы (алга таба – Диплом) хезмәт вазыйфаларын үрнәк башкарган өчен ведомство бүләге булып тора.

Диплом белән Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең бер ел эчендәге эш йомгаклары буенча югары нәтиҗәләргә ирешкән структур бүлекчәләре бүләкләнә.

2. Диплом өч дәрәҗәдә гамәлгә куела:

I дәрәҗә диплом;

II дәрәҗә диплом;

III дәрәҗә диплом.

3. Бүләкләү турында карар Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

4. Диплом белән бүләкләү Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе җитәкчесе урынбасары, структур бүлекчәләр җитәкчеләре үтенече буенча башкарыла.

5. Диплом белән бүләкләү турындагы үтенеч Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе җитәкчесе исеменә тапшырыла.

6. Диплом Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе җитәкчесе яисә аның йөкләмәсе нигезендә коллективтагы башка вазыйфаи затлар тарафыннан тантаналы шартларда бирелә.

7. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Диплом белән бүләкләнгән структур бүлекчәсенә бер тапкыр бирелә торган акчалата премия яисә тигез кыйммәтле бүләк тапшырыла.

Татарстан Республикасы Дәүләт
техник күзәтчелек идарәсенең
27.08.2021 ел, № 01-05/221-пр
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең ведомство бүләкләре (алга таба – ведомство бүләкләре) бүләкләү формасы булып тора һәм Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе) боерыгы нигезендә раслана.

2. Бүләкләү документларын карау, Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең бүләкләү, ведомство бүләкләрен рәсмиләштерү, аларга заказ бирү, аларны саклау, бирү һәм исәпкә алу эшен Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең оештыру-хокукый һәм кадрлар эше бүлеге оештыра.

3. Бүләкләү түбәндәгечә башкарыла:

еллык эшкә йомгак ясаганда;

һөнәри бәйрәмнәрне, истәлекле һәм юбилей даталарын бәйрәм иткәндә;

кешеләрнең гомере, сәламәтлеге һәм мөлкәте өчен куркынычсызлык тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне саклау өлешендә – тракторларның, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка машиналарның һәм аларга тагылмаларның аларны эксплуатацияләү барышында техник торышына, ә агросәнәгать комплексында машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү кагыйдәләре үтәлешенә дәүләт күзәтчелеге өлкәсендәге аерым күренекле казанышлар өчен;

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе җитәкчесе башлангычында.

Бүләкләү гражданнарның юбилей даталарына (50 яшьлек, 55 яшьлек, 60 яшьлек һәм аннан соң һәр 10 елдан соңгы Туган көнгә) туры китерелергә мөмкин.

4. Ведомство бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечне кузгату турындагы карар оешманың бүләкләүгә тәкъдим ителгән хезмәткәре торган штаттагы хезмәт коллективы җыелышында кабул ителә. Бүләкнең төре бүләк турындагы Нигезләмәне, бүләкләүгә тәкъдим ителгән хезмәткәрнең дәрәҗәсен һәм казанышларының характерын исәпкә алып билгеләнә.

Бүләкләү өчен һәр кандидатка әлеге Тәртинең 1 нче кушымтасында билгеләнгән форма буенча тәкъдим рәсмиләштерелә, персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык, персональ мәгълүматлар субъекты тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирелә.

Тәкъдим электрон рәвештә тутырыла, анда бозулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми. Бүләкләнүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм туу датасы паспорт буенча, шул исәптән татар телендә дә (татар милләтендәге

затлар өчен) күрсәтелә. Билгән вазыйфаның атамасы һәм оешманың исеме тулысынча, кыскартуларсыз гына языла.

Бүләкләү өчен кандидатның характеристикасында аның эштәге казанышлары һәм конкрет нәтиҗәләре, оешма, тармак яки Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе эшчәнлегенә керткән шәхси өлеше чагылдырыла. Тәкъдим бүләкләү турында үтенечне башлап җибәргән оешма җитәкчесе, коллектив җыелышы рәисе яки оешманың һөнәри берлек комитеты рәисе тарафыннан имзалана.

Тәкъдим белән бергә үтенеч тә рәсмиләштерелә, анда бүләкләүгә тәкъдим итүнең сәбәбе нигезләнә.

Бүләкләү турында үтенечне башлап җибәргән вазыйфаи затлар раслый торган материаллар сыйфатында тапшырылган тәкъдимнәрдә һәм башка документларда бәян ителгән белешмәләрнең дөреслеге һәм төгәллеге өчен шәхсән җаваплы була.

5. Ведомство бүләкләре белән бүләкләү материаллары Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә – бүләкләүгә кимендә ике ай алдан, ә юбилей, истәлекле даталарга кадәр тиешле датага кадәр кимендә бер ай алдан тапшырылырга тиеш.

Күрсәтелгән таләпләрне яисә тапшыру срокларын бозып кергән бүләкләү материаллары эшләп бетерү өчен җибәрелә яисә алыну тәртибендә карала.

6. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Рәхмәт хатына документлар бүләкләүгә тәкъдим ителгән зат үзе эшли торган республика башкарма хакимият органнарының, җирле үзидарә органнарының яисә оешманың бүләкләренә ия булган очракта тапшырыла.

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Рәхмәт хаты белән билгеләп үтелгән затлар Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Мактау грамотасы белән бүләкләүгә кимендә бер елдан соң тәкъдим ителә ала.

7. Ведомство бүләкләре белән бүләкләнгән затларны исәпкә алу оештыру-хокукый һәм кадрлар эше бүлеге, Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең бүләкләнүче хезмәткәрләрен исәпкә алу журналында, әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең ведомство бүләкләре белән бүләкләүгә
ТӘКЪДИМ ИТҮ

___________________________________________________________________________
(ведомство бүләгенең төре)

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (паспорт буенча татар һәм рус телләрендә тутырыла)

___________________________________________________________________________

2. Туган көне, ае, елы ___________________________________________________

3. Вазыйфасы һәм эш урыны _______________________________________________
(Министрлык, Дәүләт комитеты, ведомство бүлекчәсенең, берләшмәсенең, оешмасының төгәл атамасын күрсәтергә)

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

4. Белеме __________________________________________________________________

5. Гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме _____________________________________

6. Дәүләт, ведомство бүләкләре һәм Россия Федерациясе субъектларының яки оешмаларның бүләкләре _______________________________________________________

___________________________________________________________________________
(орган, учреждение, ведомство боерыгының исеме, датасы, номеры)

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

9. Гомуми эш стажы ______________________________________________________

Тармакта эш стажы ______________________________________________________

Әлеге хезмәт коллективында эш стажы ____________________________________

10. Бүләкләүгә тәкъдим ителә торган затның конкрет казанышларын күрсәтеп, характеристика

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | ________________ | ____________________ |
| (тәкъдим керткән затның вазыйфасы) | (имзасы) | (фамилиясе, исеме, ата исеме) |

«_____» ________ 20 ___ ел.

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ (кирәк булган очракта)

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | ________________ | ____________________ |
| (тәкъдим керткән затның вазыйфасы) | (имзасы) | (фамилиясе, исеме, ата исеме) |

«_____» ________ 20 ___ ел.

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибенә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең бүләкләнә торган хезмәткәрләрен исәпкә алу
ЖУРНАЛЫ

Сул ягы

| № т/с | Булекчә атамасы | Бүләкләү формасы | |
|---|---|---|---|
| | | Дәүләт (Россия Федерациясе/ Татарстан Республикасы дәүләт бүләге) | Ведомство (Мактау грамотасы, Рәхмәт хаты, Диплом) |

Уң ягы

| Бүләкләнүче зат | | Бүләкләү турында документ | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазыйфа | Документ төре | № | Дата (көне, ае, елы) | |